РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» гыйнвар 2019 ел г. Альметьевск № 104

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районының балалар
музыка, рәсем сәнгате мәктәпләрендә
һәм балалар сәнгать мәктәпләрендә
өлкәннәр өчен максатчан кертемнең
күләме турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел декабрь №273-ФЗ Федераль закон, «Балаларга өстәмә белем бирүче бюджет учреждениеләренең матди-техник базасын үстерү һәм ныгытуга бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү турында» 2005 ел 12 декабрь №597 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Раслау:

- Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар музыка, рәсем сәнгате мәктәпләрендә һәм балалар сәнгать мәктәпләрендә өлкәннәр өчен максатчан кертемнең күләме» (1 нче кушымта);

- өлкәннәр өчен рәсем сәнгате өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар рәсем сәнгате мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә максатчан кертемнең чик күләмен калькуляцияләү (үз-үзен аклый) (2 нче кушымта);

- өлкәннәр өчен музыка сәнгате өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар музыка, балалар сәнгать мәктәпләрендә вокал, музыка коралы белгечлеге буенча максатчан кертемнең иң чик күләмен калькуляцияләү (үз-үзен аклый) (3 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципаль казна, бюджет һәм автоном мәдәният һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар музыка, рәсем сәнгате мәктәпләрендә һәм

Зак. № 3063

балалар сәнгать мәктәпләрендә өлкәннәр өчен максатчан кертемнең 50 % күләмендә ташлама бирергә.

3. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар музыка, рәсем сәнгате мәктәпләрендә һәм балалар сәнгать мәктәпләрендә балаларны укыткан өчен ата-аналар взносының иң чик күләме турында» 2013 ел, 22 ноябрь,№4260карарын, Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар музыка, сәнгать мәктәпләрендә һәм балалар сәнгать мәктәпләрендә балаларны укыткан өчен ата-аналар взносының иң чик күләме турында» 2013 елның 22 ноябрендәге 4260 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел 13 мартындагы №365 карарын гамәлдән чыгарырга».

4. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы — А.Н. Подовалов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

1 нче кушымта
Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
«24» гыйнвар 2019 ел № 104
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар музыка, рәсем сәнгате мәктәпләрендә, балалар сәнгать мәктәпләрендә өлкәннәр өчен максатчан кертемнең күләме

| №№ п/п | Программаның исеме | Учреждениенең исеме | Өлкәннәр өчен максатчан түләү суммасы (сум.) | Кушымта номеры |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Өлкәннәр өчен сынлы сәнгать өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программасы. | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар рәсем сәнгате мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе. | 850 | № 2 |
| 2 | Өлкәннәр өчен музыка сәнгате өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программасы: вокал, музыка коралы (үз-үзен аклаячак) | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Р. Н.Нәгыймов исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, Әлмәт муниципаль районы «2 нче балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы « 3 нче балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы « 1 нче балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы « 2 нче балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе. | 500 (пед. сәг.) 375 (конц. сәг.) | № 3 |

Искәрмә:

Өлкәннәр өчен түләү ай саен 10 числодан дан соңга калмыйча кертелә.

Район башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
вазифаларын башкаручы О.Н. Шабалин

2 нче кушымта
Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
«24» гыйнвар 2019 ел № 104
карары белән расланды

2019 елның 1 январеннән башлап Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар рәсем сәнгате мәктәбе» өстәмә муниципаль мәгариф бюджет учреждениесендә өлкәннәр өчен рәсем сәнгате өлкәсендә өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча максатчан кертемнең чик күләмен (үз-үзен тотуга)
КАЛЬКУЛЯЦИЯЛӘҮ

| №№ п/п | Чыгымнар исеме | Суммасы сумнарда. | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Хуҗалык исәп-хисап бүлегендә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы | 612,00 | Пед.персоналның уртача хезмәт хакы 15 091,92 : 72 (айга сәг.нормасы) = 209,61 (пед.сәг. бәясе). 209,61 x 4 = 838,44 (айга сәг.бәясе) x 90 сәг. (тариф буенча ) = 75 459,60 (Төп хезмәткәрләр аена хезмәт хакы фонды (укытучылар - 6 кеше), 75 459,60 x 10 = 754 596,00<br>754 596 : 9 уку ае - 137 укучыга = 612 |
| 2 | Хезмәт хакы фондына исәпләү | 185,00 | 30,2% хезмәт хакыннан |
| 3 | Өстәмә чыгымнар | 53,00 | Хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакы 50 000 x 30,2% = 65 100 : 9 уку ае - 137 укучы = 52,80 |
|  | Барлыгы: | 850,00 |  |

Белешмә өчен: Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең хозрасчет бүлегендә 15 яшьтән һәм аннан да югары контингентта булган 137 кеше шөгыльләнә.

Район башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
вазифаларын башкаручы О.Н. Шабалин

3 нче кушымта
Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының
«24» гыйнвар 2019 ел №104
карары белән расланды

2019 елның 1 январеннән башлап Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының балалар музыка мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе муниципаль бюджет мәгариф учреждениесендә өлкәннәр өчен вокал, музыка инструменты белгечлегеннән өстәмә гомуми белем бирү программасы буенча максатчан кертемнең чик күләмен (үз-үзен тотуга)
КАЛЬКУЛЯЦИЯЛӘҮ

1 шәхси педагогик сәгать өчен исәп-хисап

| №№ п/п | Чыгымнар исеме | Суммасы сумнарда | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Хуҗалык исәп-хисап бүлегендә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (педагогик сәгать ) | 384,00 | Пед.персоналның уртача хезмәт хакы 14 745,60 : 76,8 (индивидуаль шөгыль вакытында сәгать нормасы) = 192,00 (пед. сәг.бәясе). 192 x 2 = 384,00 (сәг.бәясе) |
| 2 | Хезмәт хакы фондына исәпләү | 119,00 | 30,2% хезмәт хакыннан |
| | Барлыгы: | 500,00 | |

1 шәхси концертмейстер сәгате өчен исәп-хисап

| №№ п/п | Чыгымнар исеме | Суммасы сумнарда | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Хозрасчет бүлегендә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы (концертмейстер сәгатьләре) | 288,00 | Пед.персоналның уртача хезмәт хакы 14 745,60 : 102,4 (индивидуаль шөгыль вакытында сәгать нормасы) = 144,00 (пед. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сәг. бәясе).<br>144 x 2 = 288,00 (сәг. бәясе) |
| 2 | Хезмәт хакы фондына исәпләү | 87,00 | 30,2% хезмәт хакыннан |
| | Барлыгы: | 375,00 | |

Белешмә: өлкәннәр төркем белән шөгыльләнгәндә, сольфеджио, музыкаль әдәбият һәм ансамбль өчен педагогик сәгать бәясенең 40% ын (200 сум) максатчан взнос тәшкил итә.

Район башкарма комитеты җитәкчесенең
социаль мәсьәләләр буенча урынбасары
вазифаларын башкаручы О.Н. Шабалин